СОВЕТ
ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18.12.2020 г.Зеленодольск № 13

«2020 елның 1 гыйнварыннан Зеленодольск шәһәре территориясендә җир салымы ставкалары, тәртибе һәм түләү сроклары турында» 2019 елның 13 ноябрендәге 264 номерлы Зеленодольск шәһәре Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге, 2013 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Зеленодольск шәһәре Советы **карар итте:**

1. «2020 елның 1 гыйнварыннан Зеленодольск шәһәре территориясендә җир салымын түләү ставкалары, тәртибе һәм сроклары турында» 2019 елның 13 ноябрендәге 264 номерлы Зеленодольск шәһәре Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. «2020 елның 1 гыйнварыннан Зеленодольск шәһәре территориясендә җир салымын түләү ставкалары, тәртибе һәм сроклары турында»гы карар исемендә «һәм сроклары» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 3 пунктның өченче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«- салым түләүче оешмалар өчен салым түләү җир кишәрлегенең кадастр бәясенең процент өлешенең тиешле салым ставкасының 1/4 күләмендә аванс түләүләре белән башкарыла;».

2. Әлеге карарның 1 пункты нигезләмәләре 2020 елның салым чорында җир салымы түләүдән башлап кулланыла.

3. Әлеге карарны «Зеленодольская правда»гәҗитендә бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль-икътисадый үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре, муниципаль милек һәм эшкуарлыкны үстерү буенча даими комиссия рәисенә йөкләргә.

**Зеленодольск шәһәре Мэры,**
**Совет рәисе** **М.П. Афанасьев**